РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021 елның 31 мае 162№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» 518 номерлы карары белән расланган озак сроклы район максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актка туры килүгә бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты арасындагы «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү турында» Килешү нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» 518 номерлы карары белән расланган озак сроклы район максатчан программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Программаның паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| **Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары** | Программаны финанслау Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән һәм бүлеп бирелгән күләмнәрдә республика бюджеты |

| | |
|---|---|
| | чаралары хисабына башкарылачак<br><br>Җирле бюджет:<br><br>2021 ел-690,4 мең сум.<br><br>2022 ел-690,4 мең сум.<br><br>Республика бюджеты:<br><br>2021 ел-196,7 мең сум (спорт инвентаре)<br><br>2022 ел-196,7 мең сум (спорт инвентаре) |

1.2 Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» 518 номерлы карары белән расланган озак сроклы район максатчан программасының 1 нче кушымтасындагы «2021-2023 елларга Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» озак сроклы район максатчан программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар» бүлегенең 19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Башкару вакыты | Сумма-мең сум | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|
| 19 | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физик тәрбия спорт оешмаларын җиһазлау өчен җиһазлар, инвентарь һәм экипировка сатып алу | Әлки муниципаль районы «Спорт мәктәбе» | 2021 ел | 196,7 | Республика бюджеты |

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге начальнигына йөкләргә.

ТР Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов